СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

14 сентябрь, 2026 ел № 110

**2026 елга Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планын (программасын) раслау турында**

«Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, «Конкуренцияне яклау турында» 2006 елның 26 июлендәге 135-ФЗ номерлы Федераль закон, «Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының 2016 елның 03 ноябрендәге 93 номерлы карары белән расланган «Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкендәге мөлкәткә ия булу, аннан файдалану һәм аның белән эш итү тәртибе турындагы нигезләмәгә таянып, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның кушымтада бирелгән Фараз планын (программасын) расларга.
2. Биектау муниципаль районының «Милек һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасы» муниципаль казна учреждениесенә 2026 елга хосусыйлаштыруның фаразланган планын билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карарны Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru урнаштырып бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе, җирле үзидарә һәм җәмәгатьчелек белән элемтә буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет рәисе,
муниципаль район Башлыгы Р.Ф.Хисамутдинов

Кушымта
Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының 2026 елның 14 сентябере 110 номерлы карары белән расланды

## 2026 елга Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планы

### 1. Муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның төп бурычлары һәм юнәлешләре

1.1. 2026 елга Биектау муниципаль районы Муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру планы (алга таба текст буенча - хосусыйлаштыру планы) «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, Биектау муниципаль районы Уставы, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының 2016 елның 03 ноябрендәге 93 номерлы карары белән расланган «Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкендәге мөлкәткә ия булу, аннан файдалану һәм аның белән эш итү тәртибе турында нигезләмәгә туры китереп эшләнде.

1.2. 2026 елда хосусыйлаштыруның төп максатлары һәм бурычлары булып торалар:

- Биектау муниципаль районының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итү һәм аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен файдаланылмый торган муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштырудан җирле бюджетка салым булмаган керемнәр керүне тәэмин итү;
- эффектив булмаган мөлкәтне тотуга муниципаль район бюджетыннан чыгымнарны кыскарту;
- хосусыйлаштырылырга тиешле объектларны икътисадый нигезләнгән сайлау;
- муниципаль район бюджетының максималь керемен тәэмин итә торган хосусыйлаштыру ысулларын билгеләү.

1.3. Хосусыйлаштыру планын формалаштыруның төп принциплары:

- арендалары җирле бюджетка акчаларның тиешенчә керүен тәэмин итми торган объектларны хосусыйлаштыру планына кертү;
- объектларның үзенчәлекләрен исәпкә алып, читләштерүнең социаль-икътисадый максатка ярашлылыгы һәм хосусыйлаштыру ысулын сайлау.

1.4. Биектау муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру ысуллары һәм тәртибе Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары нигезендә билгеләнә.

Хосусыйлаштыру объектларын сатуның башлангыч бәясе «Россия Федерациясендә бәяләү эшчәнлеге турында» Федераль закон таләпләре нигезендә билгеләнгән базар бәясе нигезендә билгеләнә.

## 2. 2026 елда хосусыйлаштырылуы планлаштырылган муниципаль мөлкәт

2.1. 2026 елда хосусыйлаштырылырга тиешле муниципаль милек объектлары исемлеге әлеге Фаразлау планына кушымтада китерелгән (кушымтада бирелә).

2.2. Күрсәтелгән биналар мәйданнары фаразлана һәм объектны хосусыйлаштыруга әзерләгәндә техник инвентаризация процессында төгәлләштерелергә тиеш.

Биектау муниципаль районы Советының 2026 елның 14 сентябере 110 номерлы карары белән расланган 2026 елга Биектау муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фаразлау планына кушымта

## 2026 елга Биектау муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фаразлау планы

| № т/б | Объект исеме | Объектның урнашкан урыны | Объект мәйданы, кв.м. | Җир кишәрлегенең кадастр № | Хосусыйлаштыруның фаразланган срогы |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Җылы стоянка бинасы, билгеләнеше: торак түгел | Татарстан Республикасы, Биектау районы Дөбъяз ав., Ленин ур., 2А й. | 890,4 | 16:16:000000:2598 | III-IV квартал |
| | Җир кишәрлеге | Татарстан Республикасы, Биектау районы Дөбъяз ав., Ленин ур., 2А й. | 5536 | 16:16:090101:93 | |
| 2 | Бина - балалар бакчасы, 1 нче кат Билгеләнеше: торак булмаган | Татарстан Республикасы, Биектау районы Алат ав., Мәктәп ур., 13 й. | 146,7 | 16:16:200101:405 | III-IV квартал |
| | Кухня бинасы, 1 нче кат Билгеләнеше: торак булмаган, | Татарстан Республикасы, Биектау районы Алат ав., Мәктәп ур., 13 й. | 35,6 | 16:16:200101:451 | |
| | Җир кишәрлеге | Татарстан Республикасы, Биектау районы Алат ав., Мәктәп ур., 13 й. | 1297 | 16:16:200101:101 | |
| 3 | Балалар бакчасының торак булмаган бинасы, билгеләнеше: | Татарстан Республикасы, Биектау районы Коркачык ав., Клуб ур., 2 й., 1000 ф. | 77,9 | 16:16:310503:321 | III-IV квартал |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | торак булмаган, 1 нче кат | | | | |
| 4 | Балалар бакчасы бинасы, билгеләнеше: торак булмаган, 1 нче кат | Татарстан Республикасы, Биектау районы Коркачык ав., Клуб ур., 2 й., 1001 ф. | 29,9 | 16:16:310503:320 | III-IV квартал |
| 5 | Мәктәп бинасы, билгеләнеше: торак булмаган | Татарстан Республикасы, Биектау районы Наратлык ав., Яшьләр ур., 7й. | 529,7 | 16:16:110401:7798 | III-IV квартал |
| | Җир кишәрлеге | Татарстан Республикасы, Биектау районы Наратлык ав., Яшьләр ур., 7ж/к | 6318 | 16:16:110401:99 | |
| 6 | Мәктәп бинасы | Татарстан Республикасы, Биектау районы Коркачык ав., Үзәк ур., 38Ай. | 120,1 | 16:16:310503:497 | III-IV квартал |
| | Җир кишәрлеге | Татарстан Республикасы, Биектау районы Коркачык ав., Үзәк ур., 38Ай. | 1035 | 16:16:310503:494 | |